| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ЧЫРШЫЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 11 ноябре № 19

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Алешкино торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Алешкино торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Алешкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 1500 (Бер мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пункт территориясен төзеклəндерү (Алешкино т. п. территориясендә үлән чабу; Алешкино т. п. Үзәк урамында карт агачларны кисү)

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Алешкино торак пунктында Үзәк урам буенча грунт-вак таш юлларны ремонтлау, Алешкино торак пунктында Үзәк урам буенча юлларны кардан чистарту)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы поселогы үзидарә администрациясе бинасында Заречная ур., 25, авыл мәдәният йорты бинасында Үзәк урам 12А йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Мөхәмәтшина